РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30 март 2018 нче ел Буа шәһәре № 2-30

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау Регламентына үзгәрешләр кертү турында

06.10.2003 нче елгы № 131-ФЗ “Россия Федерациясендә җирле үзидарә органнарын оештыруның гомуми принциплары турында”, 02.05.2006 нчы елгы №59-ФЗ “Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында”, 27.11.2017 нче елгы № 355-ФЗ “ “Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү турында” Федераль законнарына туры китереп, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Буа район Советы Карары белән 12.11.2014 нче елда расланган №3-42 “Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау Регламенты турында” Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау Регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 3 нче бүлектә:

3.4 пунктны түбәндәгечә үзгәртергә:

“3.4. Җирле үзидарә органнарына яисә вазифаи затка электрон документ формасында кергән мөрәҗәгать 02.05.2006 нчы елгы № 59-ФЗ “Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” Федераль законда күрсәтелгән тәртиптә каралырга тиеш. Гражданин мөрәҗәгатендә мәҗбүри рәвештә үзенең фамилиясен, исемен, әтисенең исемен (соңгысы – әгәр булса), җавап, мөрәҗәгатьнең тапшырылуы турында хәбәр җибәрелергә тиешле электрон почта адресын күрсәтергә тиеш. Гражданин шундый мөрәҗәгатенә кирәк булган документларны һәм электрон формадагы материалларны теркәү хокукына ия”.

1.2. 4 нче бүлектә:

4.1. пунктны түбәндәгечә үзгәртергә:

“4.1. Мөрәҗәгать нигездә каралмый, әгәр:

1) Гражданның мөрәҗәгатендә элегрәк берничә тапкыр язмача җавап бирелгән сораулар булганда, шул ук вакытта мөрәҗәгатьтә яңа дәлилләр китерелмәсә, әлеге мөрәҗәгать һәм алданрак җибәрелгән мөрәҗәгатьләр бер үк органга яисә бер үк вазифаи затка җибәрелгән булса;

1.1. Җирле үзидарә органнарына яисә вазифаи затка язмача кергән мөрәҗәгатьтә 02.05.2006 нчы елгы № 59-ФЗ "Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" Федераль законның 10 нчы статьясының 4 нче пунктына туры китереп, сорауның җавабы әлеге җирле үзидарәнең "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган булса, мөрәҗәгатьне җибәрүчегә мөрәҗәгате теркәлгәннән соң җиде көн эчендә "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге рәсми сайтның электрон адресы хәбәр ителә, шул ук вакытта суд карарына ризасызлык белдереп язылган мөрәҗәгать кире кайтарылмый;

2) язмача мөрәҗәгать тексты укырлык булмаганда;

2.1) язмача мөрәҗәгать тексты тәкъдим, гариза яисә шикаятьнең асылын аңларга мөмкинлек бирмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми, мөрәҗәгать, компетенцияләренә туры китереп, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә вазифаи затка җибәрелми, бу турыда мөрәҗәгать теркәлгәннән соң җиде көн эчендә мөрәҗәгатьне җибәрүче гражданинга хәбәр ителә.

3) мөрәҗәгать эчтәлегендәге сораулар буенча закон көченә кергән суд карары булганда;

4) мөрәҗәгатьтә вазифаи затның, шулай ук аның гаиләсенең тормышы, сәламәтлеге һәм милегенә куркыныч тудыручы, әдәпсез яисә кимсетүче җөмләләр булганда;

5) мөрәҗәгатьтә фамилия яисә җавап бирү өчен почта адресы күрсәтелмәгән булса;

6) мөрәҗәгатьтә куелган сорауга федераль закон белән саклана торган дәүләт серләре ачылырга мөмкин булган мәгълүматларны таратмыйча җавап биреп булмаганда.

Әгәр дә элегрәк мөрәҗәгатендә куелган сораулары буенча аңа җавап бирелгән булса, гражданинны шәхси кабул итү вакытында мөрәҗәгатен алга таба карау туктатыла.

Мөрәҗәгатьтә куелган сорауларга җавап биреп булмаганда, соңрак бу сәбәпләр бетерелгән очракта, гражданин мөрәҗәгатен тиешле дәүләт органына, җирле үзидарә органына, тиешле вазифаи затка яңадан җибәрергә хокуклы.

1.3. 7 нче бүлектә:

7, 8 нче бүлекнең 7.8.1 пунктын түбәндәгечә үзгәртергә:

"7.8.1 Мөрәҗәгатькә җавапка җирле үзидарә җитәкчесе, вазифаи зат яисә вәкаләтле зат тарафыннан кул куела";

7, 8 нче бүлекнең 7.8.2 пунктын түбәндәгечә үзгәртергә:

"7.8.2 Җавап текстында җавап ачык, эзлекле, кыска, хатта куелган сорауларга тулы аңлатмалар булырга тиеш. Шикаятьтә күрсәтелгән фактлар расланса, җавапта гражданинның мөрәҗәгате буенча нинди чаралар күрелүен күрсәтергә кирәк.

Мөрәҗәгатькә җавап җирле үзидарә органына яисә вазифаи затка электрон документ формасында кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресына

электрон документ формасында һәм җирле үзидарә органына яисә вазифаи затка язма формада кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресына язма формада җибәрелә. Моннан тыш, җирле үзидарә органына яисә вазифаи затка кергән мөрәҗәгать эчтәлегендә төрле затлар мәнфәгатьләренә кагылучы, аерым алганда төрле затларга карата чыгарылган суд карарына ризасызлык белдергән тәкъдим, гариза яисә шикаять булса, шул исәптән суд карарына ризасызлык белдерү тәртибен аңлату 02.05.2006 нчы елгы № 59-ФЗ "Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" Федераль законның 6 нчы статьясы 2 нче кисәге таләпләре буенча әлеге җирле үзидарә органының "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдәге рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин";

2. Әлеге Карар рәсми бастырып чыгару көненнән үз көченә керә һәм районның рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы Рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Интернет мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru. адресы буенча Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне үз җаваплылыгымда калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Буа муниципаль районы Советы рәисе М. А. Җаббаров